**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«29» марта 2019 ел Мәләкәс поселогы №50/2

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милегендә булган җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

Тукай районы прокуроры протесты нигезендә, Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гянварендәге 7-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Уставы, Мәләкәс авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милегендә булган җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны рациональ куллану, саклау һәм яңадан торгызу максатында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милегендә булган җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәне кушымтадагыча расларга.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 июндәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә, физик һәм юридик затларның хосусый милегендә булган җирләргә кермәгән яшел Мәләкәс кисү тәртибе турында нигезләмәне раслау турында»№ 42/2 санлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгүләмати стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны районның рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе В.И.Артемьев